ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2023 Олы Кайбыч ав. № 203

Җәйге чорда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә тәрбияләнүчеләр кабул итүне вакытлыча туктатып тору турында

Җәйге чорда балаларның аз йөрүен исәпкә алып, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә ремонт эшләрен башкару зарурлыгы һәм бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 июненнән 31 августына кадәр вакытлыча җәйге чорга ябарга:

- «ТР Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ (мәктәпкәчә төркем);
- ТР Кайбыч муниципаль районының «М.К.Кузьмин исемендәге Иске Тәрбит урта» гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ (мәктәпкәчә төркем);
- «ТР Кайбыч муниципаль районының Иске Чәчкаб төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ (мәктәпкәчә төркем);
- «ТР Кайбыч муниципаль районының Ульянково төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ -«Надеждино «Земляничка» балалар бакчасы».

2. 2023 елның 1 июленнән 31 августына кадәр вакытлыча җәйге чорга ябарга:

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай балалар бакчасы» МБМББУ;
- «ТР Кайбыч муниципаль районы Олы Тәрбит «Карлыгач» балалар бакчасы» МБМББУ;
- «ТР Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ (мәктәпкәчә төркем);
- ТР Кайбыч муниципаль районының «Р.Кәлимуллин исемендәге Борындык төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ (мәктәпкәчә төркем);

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Кайбыч «Сандугач» балалар бакчасы» МБМББУ;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки «Чулпан» балалар бакчасы» МБМББУ;

- ТР Кайбыч муниципаль районының Колаңгы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ (мәктәпкәчә төркем);

- «ТР Кайбыч муниципаль районының Ульянково төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ -«ТР Кайбыч муниципаль районы Ульянково «Солнышко» балалар бакчасы»;

- «ТР Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән «Аленушка» балалар бакчасы» МБМББУ;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти «Буратино» балалар бакчасы» МБМББУ.

3. 2023 елның 1 августыннан 31 августына кадәр вакытлыча җәйге чорга ябарга:

- «ТР Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье «Каенкай» балалар бакчасы» МБМББУ.

4. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгына:

4.1. педагогик хезмәткәрләргә һәм техник персоналга узган уку елы өчен чираттагы отпускларны бирүне;

4.2. педагогик хезмәткәрләргә һәм техник персоналга чираттагы отпусклар тәмамланганнан соң җәйге чорга мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен ябуга бәйле рәвештә хезмәт хакын сакламыйча ял бирүне тәэмин итәргә

5. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ һәм Кайбыч муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә җәйге чорга тәрбияләнүчеләрне кабул итүне туктатып торганда мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр тарафыннан аларда тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору чорына мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү тәртибенә таянып эш итәргә.

6. Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районының Интернет информацион-телекоммуникацион челтәрендә http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарырга .

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров